РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» июнь 2025 ел г. Альметьевск № 1373

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 17 апрелендәге 238 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 962 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы,

заказ № 1-851

2021 елның 2 мартындагы 281 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2451 номерлы, 2024 елның 27 июнендәге 2199 номерлы, 2024 елның 31 октябрендәге 3539 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 1 пунктының 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табл.№ 1

| № п/п | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Идарә башлыгы | 30 316,0 |
| 2 | Оператив дежурный | 23 320,0» |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольтотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М. Каюмовка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова